Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 30 апреле 50№

Әлки муниципаль районы Советының 2012 елның 2 августындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә гражданнар арасында сораштыру билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» гы 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, 2020 елның 20 июлендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 236-ФЗ номерлы Федераль закон, "Әлки муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Әлки муниципаль районында гражданнарның җирле үзидарәне гамәлгә ашыру хокукын гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук җирле үзидарә органнары карарлар кабул иткәндә халыкның фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу өчен Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы территориясендә гражданнар арасында сораштыру үткәрү һәм билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Гражданнарның инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча сораштыруда муниципаль берәмлек халкы яисә аның инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән өлешендәге уналты яшькә җиткән кеше катнашырга хокуклы.";

5.7 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карар Әлки муниципаль районы Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен "Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайты кулланыла ала. Әлки муниципаль районы Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турындагы карарында билгеләнә:";

түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә: "7) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтыннан файдаланып, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.";

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин